| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.07.2019 №813-па

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының, 2011 елның 3 февралендәге 76-п номерлы карары белән расланган, хокук бозуларны кисәтү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Татарстан Республикасы территориясендә коралның, хәрби кирәк-яракларның һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешен кисәтү чаралары турында" 1995 елның 5 августындагы 545 номерлы "Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында" 2019 елның 1 апрелендәге 255 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының "Хокук бозуларны кисәтү буенча район ведомствоара комиссиясе составын һәм нигезләмәсен яңа редакциядә раслау турында" гы 2011 елның 3 февралендәге 76-п номерлы карары белән расланган, хокук бозуларны кисәтү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.1. пунктын түбәндәге эчтәлеккә ия булган сигезенче абзац белән тулыландырырга:

" - гражданнарның гаризалары буенча, ирекле тапшырылган корал (коралның төп өлешләре, хәрби кирәк-яраклар, коралга патроннар, шартлаткыч матдәләр, шартлаткыч җайланмалар) өчен акчалата түләүне гамәлгә ашыру буенча бәяләмәләрне карый һәм бирә".

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов